МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.06.2021 г.Казань № 437

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 2 июлендә 7793 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Граж-даннарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең админис-тратив регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш биру-челәргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ рег-ламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 ел-ның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.05.2016 №261, 11.07.2018 №532, 08.05.2019 №341,

14.11.2019 №1030, 30.04.2020 №279, 22.06.2020 №451, 28.09.2020 №673 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 22.06.2021 №437 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.5 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче (гражданин) 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыра һәм түбәндәгеләрне күрсәтә:

- Россия Федерациясе паспорты яки аны алмаштыра торган документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);

- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын раслаучы документлар (чит ил гражданнары өчен);

- шәхесне раслаучы документлар (гражданлыгы булмаган затлар өчен).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче (гражданин), шул исәптән, түбәндәге документларны да күрсәтә ала:

хезмәт кенәгәсенең (булган очракта) һәм (яки) хезмәткәрнең хезмәт эшчәнлеге турында (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорлар өчен) белешмәнең тиешле рәвештә таныкланган кәгазь күчермәсе яки Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган электрон документ формасында;

белем алу һәм (яки) квалификация турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында һәм белем алуга бәйле, чит ил дәүләте территориясендә бирелгән документлар һәм аларның нотариаль яктан таныкланган рус теленә тәрҗемәсе;

белем һәм (яки) квалификация турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында хәрби һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче хәрби мәгариф оешмалары тарафыннан бирелә торган, шулай ук 1992-1995 елларда Россия Федерациясе территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашырган оешмалар тарафыннан бирелгән документлар;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хезмәт эшчәнлеген туктатуны раслый торган документлар (гражданлык хокукы характерындагы килешү, шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлекне туктату турында документ, нотариус вәкаләтләрен туктату турында документ, адвокат статусын туктату турында документ);

гражданинны (мөрәҗәгать итүчене) туры килә торган эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган, Халыкны эшкә урнаштыру турындагы законның 5 статьясында каралган категориягә кертүне раслый торган документлар (иректән мәхрүм итү урыннарыннан чыгару турында белешмә; гражданинны качак яки мәҗбүри рәвештә күченә торган зат буларак тануны раслый торган, билгелән-гән тәртиптә федераль миграция хезмәте органнарыннан бирелгән документ; Чернобыль һәлакәте һәм башка радиация һәлакәтләре һәм катастрофалары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданин таныклыгы; хәрби билет, хезмәттән җибәрү нигезен күрсәтеп, хәрби хезмәттән җибәрү турындагы боерыктан өземтә, хәрби частьтән белешмә; күпбалалы гаилә таныклыгы, гражданинның бердәнбер ата-ана булуын раслый торган документ).

Хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр эшсез гражданин тарафыннан түбәндәгечә алынырга мөмкин:

тиешле рәвештә таныкланган кәгазь документ яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (эшкә бирүчедә булган очракта) белән имзаланган электрон документ формасында соңгы эш урыны буенча эш бирүчедән (әлеге эш бирүчедә эшләгән чор өчен);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә тиешенчә расланган кәгазь документ рәвешендә;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан тиешле рәвештә расланган кәгазь документ рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган элек-трон документ рәвешендә.

Алга таба янә мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче (гражданин) түбәндәгеләрне күрсәтә:

- Россия Федерациясе паспорты яки аны алмаштыра торган документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);

- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын раслаучы документлар (чит ил гражданнары өчен);

- шәхес таныклый торган документлар (гражданлыгы булмаган затлар өчен);

хезмәт кенәгәсенең (булган очракта) һәм (яки) хезмәткәрнең хезмәт эшчәнлеге турында (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорлар өчен) белешмәнең тиешле рәвештә таныкланган кәгазь күчермәсе яки Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган электрон документ формасында (билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар өчен).

Чит телдә төзелгән документлар рус теленә тәрҗемә ителергә тиеш. Тәрҗемәнең дөреслеге һәм тәрҗемәче имзасының чын булуы нотариус тарафыннан таныкланган булырга тиеш.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче (эш бирүче) 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыра һәм түбәндәгеләрне күрсәтә:

- 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча тутырылган «Хезмәткәрләргә ихтыяҗ, буш эш урыннары (ва-кантлы вазыйфалар) булуы турында мәгълүматлар» бланкы (алга таба – Хезмәткәрләргә ихтыяҗ турында мәгълүматлар);

- Россия Федерациясе паспорты яки аны алмаштыра торган документ (эшкә алучы затлар – Россия Федерациясе гражданлыгына ия булган физик затлар өчен);

- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документлар (эшкә алучы затлар – чит ил гражданлыгына ия булган физик затлар өчен);

- шәхесне таныклый торган документлар (эшкә алучы затлар – гражданлыгы булмаган физик затлар өчен).

Алга таба янә мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче (эш бирүче) Хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында белешмә күрсәтә (җибәрә).

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза кәгазен мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Порталында урнаштырылган. Мөрәҗәгать итүчегә гариза тапшыру ысулын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителә: халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, почта аша, электрон почтаны да кертеп, факсимиль элемтә ярдәмендә яисә гади электрон имза белән имзаланган элек-трон документ формасында, шул исәптән Татарстан Республикасы порталын-нан файдаланып, яисә гаризаны күпфункцияле үзәк, читтәге эш урыны аша тапшыру юлы белән.

Мөрәҗәгать итүче (гражданин) туры килә торган эш эзләүдә булышлык итүдә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, «Работа в России» гомумроссия вакансия-ләр базасы мәгълүмат-аналитика системасындагы шәхси кабинетында яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порта-лы» федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетында туры килә торган эш эзләүдә булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада гариза биреп, халыкның мәшгульлек үзәгенә читтән торып мөрәҗәгать итә ала (әлеге абзац таләбе 2021 елның 31 июленә кадәр гамәлдә була)»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хоку-кый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«524н номерлы Федераль стандартның 5, 13, 14 пунктлары, 16 пункты-ның 1 пунктчасы, 22 пунктының 1 пунктчасы; Россия Федерациясе Хөкүмә-тенең 2012

елның 7 сентябрендәге 891 номерлы карары белән расланган Кагый-дәләрнең 3, 4 пунктлары; 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 13 нче кушымта; 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлеше; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 8 апрелендәге 460 номерлы кара-ры белән расланган Туры килә торган эш эзләү максатларында гражданнарны эшсезләр сыйфатында теркәү, шулай ук билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләр түләү буенча вакытлыча кагыйдәләрнең 2 пункты»;

2.6 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомстволар арасында электрон хезмәттәшлек итү тәртибендә алына торган документлар:

- белем турында документлар, белем турында һәм квалификация турында документлар, квалификация турында документлар, белем алу турында документлар, фәнни дәрәҗәләр һәм фәнни исемнәр турында документлар;

- соңгы эш урыны буенча соңгы 3 ай өчен уртача хезмәт хакы турында белешмә;

хезмәт кенәгәсенең (булган очракта) һәм (яки) хезмәткәрнең хезмәт эшчәнлеге турында (2020 елның 1 гыйнварыннан соңгы чорлар өчен) белешмәнең тиешле рәвештә таныкланган кәгазь күчермәсе яки Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган электрон документ формасында;

- индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә, инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган белешмә, шулай ук организмындагы бозылган функцияләрне һәм яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, инвалид өчен ме-дик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан киңәш ителә торган хез-мәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен кирәкле белешмәләр (кеше-нең организмында авырулар, травма алу һәм дефектлар нәтиҗәсе белән аңла-тыла торган бозылган функцияләрне исәпкә алып, күрсәтелгән һәм күрсәтел-мәгән хезмәт эшчәнлеге төрләре турында; инвалидны эшкә урнаштыру өчен махсус эше урыны җиһазлау (тәэмин итү) буенча; эшкә яраклаштыру буенча; эш шартлары турындагы киңәшләр белән);

- инвалидның организмындагы бозылган функцияләрен һәм яшәешендәге чикләүләрен исәпкә алып, киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләр (индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә);

- юридик затны (шәхси эшкуарны, крестьян (фермер) хуҗалыгын) дәүләт теркәвенә алу турында, белешмәләрне Юридик затларның (Шәхси эшкуарларнын) бердәм дәүләт реестрына кертү турында белешмәләр (алга таба – дәүләт теркәве турында таныклык);

- чит ил юридик затларының аккредитацияләнгән филиаллары, вәкилләкләрен дәүләт реестрына тиешле язуны кертү турында белешмәләр;

- аерым шәхси счетның иминият номеры.

Ведомстволар арасында җибәрелә торган мөрәҗәгать ведомстволар арасында электрон хезмәттәшлек итүнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташты-

рыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон документ формасында җибәрелә.

Инвалидлар категориясенә кертелгән гражданнар медик-социаль экспертиза учреждениесеннән бирелгән индивидуаль тернәкләндерү программасын үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы. Мөрәҗәгать итүче (эш бирүче) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә күчермәсен яисә нотариаль тәртиптә расланган күчермәне, мөмкинлеге булган очракта, электрон формада тапшырырга (җибәрергә) хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче (эш бирүче) тарафыннан Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан күчермәнең яисә нотариаль тәртиптә расланган күчермәнең тапшырылмавы (җибәрелмәве) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Мөрәҗәгать итүче (гражданин) шәхси (персональләштерелгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында да, теркәлүне раслый торган документ тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче (гражданин) тарафыннан шәхси (персональләште-релгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документны тап-шырмау, шул исәптән электрон документ формасында да, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга (күрсәтергә) хокуклы документларны алу ысуллары һәм аларны тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актла-ры нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуын-дагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып

торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хоку-кый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«524н номерлы Федераль стандартның 13 пункты; «Россия Федерация-сендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясының 11 пункты; «Россия Федера-циясендә чит ил инвестицияләре турында» 1999 елның 9 июлендәге 160-ФЗ но-мерлы Федераль законның (алга таба – 1999 елның 9 июлендәге 160-ФЗ но-мерлы Федераль закон) 4 статьясының 3 өлеше; 524н номерлы Федераль стан-дартның 13, 14 пунктлары; 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлеше»;

3.5.3.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.7.2. Тапшырылган документлар составында һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, эшсез гражданин мөстәкыйль тапшырырга хокуклы булган документлар (белешмәләр) булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдә-мендә сорала торган белешмәләр белән эш итүче дәүләт органнарына тиешле рәсми мөрәҗәгатьне (рәсми мөрәҗәгатьләрне) җибәрә:

- белем турында документлар, белем турында һәм квалификация турында документлар, квалификация турында документлар, белем алу турында документлар, фәнни дәрәҗәләр һәм фәнни исемнәр турында документлар;

- соңгы эш урыны буенча соңгы 3 ай өчен уртача хезмәт хакы турында белешмә;

хезмәт кенәгәсенең (булган очракта) һәм (яки) хезмәткәрнең хезмәт эшчәнлеге турында (2020 елның 1 гыйнварыннан соңгы чорлар өчен) белешмәнең тиешле рәвештә таныкланган кәгазь күчермәсе яки Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган электрон документ формасында;

- индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә, инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган белешмә, шулай ук организмындагы бозылган функцияләрне һәм яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, инвалид өчен медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен кирәкле белешмәләр (кешенең организмында авырулар, травма алу һәм дефектлар нәтиҗәсе белән аңлатыла торган бозылган функцияләрне исәпкә алып, күрсәтелгән һәм күрсә-телмәгән хезмәт эшчәнлеге төрләре турында; инвалидны эшкә урнаштыру өчен махсус эше урыны җиһазлау (тәэмин итү) буенча; эшкә яраклаштыру буенча; эш шартлары турындагы киңәшләр белән);

- инвалидның организмындагы бозылган функцияләрен һәм яшәешендәге чикләүләрен исәпкә алып, киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләр (индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә);

- дәүләт теркәве турында таныклык;

- чит ил юридик затларының аккредитацияләнгән филиаллары, вәкил-

лекләрен дәүләт реестрына тиешле язуны кертү турында белешмәләр;

- аерым шәхси счетның иминият номеры.

3.7.1 һәм 3.7.2 пунктларда билгеләнә торган процедуралар гариза килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Халыкның мәшгульлек үзәгенә яисә Министрлыкка кергән шикаять ул кергән көненнән соңгы икенче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга яисә югары торучы органга (андый булган очракта) килгән шикаять аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә каралырга тиеш.».